**Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

2021 елның 09 Июнь № 10

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы

К А Р А Р  Б И Р Д Е :

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Ошторма-Юмья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының 2014 елның 04 февральдагы 1 номерлы карары (2016 елның 31 декабрендәге 38 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 15 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 23 номерлы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Ошторма-Юмья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә», 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы С.Г. Антонов

ОГРН 1021607752737
ИНН 1623001692